ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МАМЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

«19» октябрь 2021 ел № 33

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге Советының 18.05.2014 ел, № 95 карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 20.07.2020 ел, № 236-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге Советының 18.05.2014 ел, № 95 карары) белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге территориаль иҗтимагый үзидарәсен оештыру тәртибенә (алга таба-тәртип), тәртипнең 14 статьясындагы 4 пунктын түбәндәгечә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«4. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыручы гражданнар җыелышының (конференцияләренең) аерым вәкаләтләренә керә:

1) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары структурасын билгеләү;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә уставын кабул итү, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарын сайлау;

4) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгеләү;

5) территориаль иҗтимагый үзидарәнең керемнәре һәм чыгымнары сметасын һәм аның үтәлеше турындагы хисапны раслау;

6) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы хисапларны карау һәм раслау;

7) инициативалы проектны тикшерү һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.».

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга һәм җирлек территориясендә мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Мамык авыл җирлеге
Советы рәисе В.В. Рыжков